ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ
КОМЫРГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

СОВЕТ КОМОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422758 Республика Татарстан Атнинский район с. Коморгузя. Тел. 3-20-22

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» ноябрь 2019 ел. № 9

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2019 елның 10 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа торак пунктында үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты 23 ноябрь 2019 ел 19.00 сәг.тән 20.00 сәг.кадәр;

- үткәрү урыны — Комыргуҗа авылы, Пионер урамы урамы, 22 йорт, Комыргуҗа мәдәният йорты залы;

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 18 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Комыргуҗа авылы, Татарстан урамы, 40 йорт;

- сайлау хокукына ия булган Комыргуҗа торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Комыргуҗа торак пункты халкына массакүләм мәгълумат чараларында гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум

күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-Комыргуҗа авылы зиратын чистарту өчен чыгымнар тоту;

-Комыргуҗа авылын чистарту,төзекләндерү өчен чыгымнар тоту;

-Комыргуҗа авылындагы чишмә эйләнэсен төзекләндерү өчен чыгымнар тоту;

-Комыргуҗа авылында урамнарны яктырту һәм яктырткычлар, материаллар сатып алу (яктырткычларны, чыбыкларны ремонтлау, лампаларны алыштыру) буенча хезмәт күрсәтү;

-Комыргуҗа авылында урам тренажёрлары алу һәм урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълумат-телекоммуникация челтәрендә тубәндаге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Комыргуҗа авылы, Татарстан урамы, 40 йорт, Комыргуҗа авылы, Пионер урамы, 22 йортлардагы мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4.Әлеге карар ул халыкка игълан ителган көннән уз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы: Ф.Ф.Низамиев